ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

15 05 2019 г. № 235

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Халыкның ялын оештыру һәм мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр белән тәэмин итү һәм халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, китапханәләрнең китапханә фондлары сакланышын тәэмин итү һәм комплектлаштыру өчен шартлар тудыру буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» 2016 елның 16 ноябрендәге 1597 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Түбән Кама шәһәр прокуратурасының 2019 елның 24 апрелендәге 02-08-07 2019 номерлы таләпләрен үтәү йөзеннән, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Халыкның ялын оештыру һәм мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр белән тәэмин итү һәм халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, китапханәләрнең китапханә фондлары сакланышын тәэмин итү һәм комплектлаштыру өчен шартлар тудыру буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» (алга таба – карар) 2016 елның 16 ноябрендәге 1597 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1-нче кушымтасында:

2.1. пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектларына һәм җирле үзидарә органнарына мәдәният оешмалары челтәрен үстерү һәм халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2017 елның 2 августындагы Р-965 номерлы Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының боерыгы»;»;

2.1. пунктының уникенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.1. пунктының унҗиденче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

10.1. пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген бирүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:»;

карарның 2 нче кушымтасында:

2.1. пунктының унбишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.1. пунктының унҗиденче абзацында «тармакара нормалар» сүзеннән соң «вакыт» сүзен өстәргә;

2.1. пунктының егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Китапханә фонды составына керүче документларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2012 елның 8 октябрендәге 1077 номерлы боерыгы;»;

2.1. пунктының егерме икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6.2. пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган янгын куркынычсызлыгы таләпләренә; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә;»;

10.1. пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген бирүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН